**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2025 Балык Бистәсе штп. № 41пи

2025 елның I кварталына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе штп. да торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2019 №888 карары белән расланган “Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү” дәүләт программасының “Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" ярдәмче программасын тормышка ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы” НПның бәяләр диапазонын билгеләү турында 07.02.2025 № 57 хатын игътибарга алып КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту буенча чаралар үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе штп. да торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясен 2025 елның I кварталына 51 020,00 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов